| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2025 № 6

**Муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектын тартып алу турында**

Россия Федерациясе Җир кодексының VII.1 бүлегенең 49 нчы статьясына, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279, 281 статьяларына, Татарстан Республикасы Җир кодексының 5 статьясына таянып, районның социаль-икътисадый инфраструктурасын яхшырту, шулай ук «Казаклар урамы, Советская урамы һәм Собор мәйданы белән чикләнгән территорияне төзекләндерү» проектын – Кече шәһәрләр һәм тарихи торак пунктлар категориясендә гамәлгә ашыру максатында

**карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль ихтыяҗлар өчен түбәндәге күчемсез мөлкәт объектларын тартып алырга:

кадастр номеры 16:05:010601:526, мәйданы 218 кв. м. булган җир кишәрлеге, урнашкан адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Алексеевск ш. т. п., Советская мәйданы, 4 йорт, җир категориясе: торак пункт җирләре, рөхсәт ителгән файдалану төре: җитештерү базасы өчен;

торак булмаган бина (гараж), кадастр номеры 16:05:010601:521, мәйданы 130,4 кв.м., урнашкан адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Алексеевск ш. т. п., Советская мәйданы, 4 йорт.

2. Җир кишәрлеген тартып алуга бәйле рәвештә барлыкка килә торган чыгымнарны базар бәясе буенча капларга дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт

объектын тартып алу турында килешү төзергә.

4. Тартып алу турында карар кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә:

- карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында: http://alekseevskiy.tatarstan.ru урнаштырырга,

- җир кишәрлеген тартып алу турындагы әлеге карарның күчермәсен тартып алына торган күчемсез мөлкәтнең хокук иясенә тапшырылуы турында хәбәрнамәле хат белән почта адресына яисә шәхсән җибәрергә.

- җир кишәрлеген тартып алу турындагы әлеге карарның күчермәсен Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Алексеевск шәһәр җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.К. Свистунов**